| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.10.2017 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2549** |
|---|---|---|

«Зеленодольск муниципаль районының проект комитеты турында» нигезләмәне раслау хакында

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 124 номерлы карары белән (2017 елның 12 июлендәге 203 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге планлы чорга Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 231 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турында» 231 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының проект комитеты турында» нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты составын 2 нче кушымта каралганча расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В.Кадыйровага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017елның 06 октябрендәге 2549 номерлы карарына
1 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПРОЕКТ КОМИТЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

Проект Комитеты Зеленодольск муниципаль районының коллегиаль органы булып тора һәм Зеленодольск муниципаль районында эшчәнлекне планлаштыруны һәм контрольдә тотуны, проектларны гамәлгә ашыруны, контроль чараларга һәм күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итү максатларында төзелгән.

Проект Комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Проект комитетының бурычлары һәм хокуклары

Проект комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

- проект идарәсе системасында эшләнә һәм гамәлгә ашырыла торган проектларны муниципаль һәм республика реестрына кертү турында карар кабул итү;
- проектлар (проект портфельләре)паспортларын раслау һәм эшләтеп җибәрү, аларны ябу һәм кабул итү турында карар кабул итү;
- проектлар җитәкчеләрен һәм проектлар портфельләре җитәкчеләрен билгеләү;
- Зеленодольск муниципаль районының Проект офисы тарафыннан әзерләнгән тәкъдимнәр нигезендә структур бүлекчәләрнең проект офисларын төзү турында карар кабул итү;
- проектларны типларның берсенә кертү турында карар кабул итү.

Проект комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

-Зеленодольск муниципаль районында проект эшчәнлеге документларын расларга;

- җирле үзидарә органнарының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, предприятие һәм оешмаларның вазыйфаи затларын Проект комитеты утырышларына чакырырга.

-Проект комитетына йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләрне һәм материалларны соратып алырга.

## III. Проект комитетының составы һәм эшләрен оештыру

Проект комитеты Проект комитеты рәисе, Проект комитеты рәисе урынбасары, Проект комитеты әгъзалары һәм җаваплы секретарь составында төзелә.

Проект комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тора.

Проект комитеты рәисе:

- Проект комитеты эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- Проект комитетының эш планын раслый;
- Проект комитетының утырышларын билгели һәм көн тәртибен раслый;
-Проект комитеты утырышлары белән җитәкчелек итә;
- Проект комитетының утырышлары беркетмәләренә кул куя;
-Проект комитеты утырышларында Проектлау комитеты әгъзалары булмаган затларны тавыш бирү хокукыннан башка катнашуга җәлеп итү турында карар кабул итә;
- әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә өстәмә вәкаләтләрне исәпкә алып, Проект Комитеты әгъзаларына бирелгән барлык хокуклардан файдалана;
- Проект Комитеты эшчәнлеге кысаларында күрсәтмәләр бирә һәм аларның үтәлеше барышын тикшереп тора.

Проектлар Комитеты рәисе урынбасары Проект Комитеты рәисе итеп билгеләнә:

- Проект Комитеты рәисе булмаганда, аның функцияләрен башкара;
-Проект Комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә;
-Проект Комитеты карарларының үтәлешен контрольдә тота.

Проект комитеты әгъзалары:

- Проект Комитеты утырышларында һәм карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашалар;
- Проект Комитеты утырышларында докладлар белән чыгыш ясыйлар;
-Проект Комитеты каравына тикшерелә торган мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар тапшыралар;
- Проект Комитеты әгъзасы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле Проект Комитеты рәисенең йөкләмәләрен, шулай ук Проект Комитеты карарын үтиләр;
- Проект Комитетында була алмаганда вәкаләтле вәкилгә үз вәкаләтләрен тапшыралар (бу хакта алдан ук җаваплы секретарьгә хәбәр итеп);
-Проект Комитетының чираттан тыш утырышы турында тәкъдимнәр кертәләр;
-көн тәртибенә фикер алышу өчен сораулар кертү турында тәкъдимнәр кертәләр;

- Проект Комитеты карарларын әзерләүдә һәм кабул итүдә катнашалар.

Проект Комитетының җаваплы секретаре Проект Комитеты рәисе белән билгеләнә:

-Проект комитеты утырышын әзерләүне оештыра;

-Проект комитеты утырышы беркетмәсен алып бара;

- утырышларны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында Проект Комитеты әгъзаларына хәбәр итә, шулай ук Проект Комитеты әгъзаларын кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

-Проект Комитеты рәисе кушуы буенча башка вазыйфаларны үти.

Проект Комитеты утырышлары аена кимендә бер тапкыр уздырыла.

Проект Комитеты утырышларында беркетмә алып барыла. Проект комитеты карарлары Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, предприятие һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

Проект Комитетының җаваплы секретаре Проект комитеты әгъзасы булып тормый һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән Проект комитеты әгъзаларының хокукларына һәм бурычларына ия түгел.

Проект Комитеты утырышында катнаша алмаган очракта, Проект Комитеты әгъзасы бу хакта Проект Комитетының җаваплы секретаренә утырыш уздырылуның билгеләнгән көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Проект Комитеты утырышында катнашырга вәкаләтле затны күрсәтеп хәбәр итәргә тиеш. Проект Комитеты әгъзасын алмаштыручы затның тавыш бирү хокукы юк.

Проект Комитеты утырышы, әгъзаларның яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип таныла.

Проект Комитетының һәр әгъзасы бер тавышка ия. Карарлар утырышта катнашучы Проект Комитеты әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигезләнгән очракта, Проект Комитеты рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Проект Комитеты утырышында катнаша алмаган Проект Комитеты әгъзалары Проект Комитетының җаваплы секретаренә Проект Комитеты утырышы көн тәртибе мәсьәләсе буенча үз фикерләрен җиткерә ала.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017елның 06 октябрендәге 2549 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының Проект комитеты составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Тыгин Александр Васильевич | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы - Зеленодольск муниципаль районының Проект комитеты рәисе |
| 2 | Кадыйрова Светлана Викторовна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - проект эшчәнлеге координаторы, Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты рәисе урынбасары |
| 3. | Чернова Марина Борисовна | Зеленодольск муниципаль районының «Зелёный Дол» инвестиция үзәге» автоном учреждениесе җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты секретаре |
| 4 | Нуриева Гүзәл Наил кызы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы |
| 5 | Дёгтева Ольга Павловна | «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 6 | Герасимов Юрий Николаевич | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш архитекторы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы |
| 7 | Стерякова Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы |
| 8 | Ячанов Алексей Викторович | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 9 | Соловьев Алексей Вячеславович | ЗМР эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы рәисе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Гончаров Олег Владимирович | Бәйсез эксперт - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 11 | Шошин Константин Леонидович | Сколково проект идарәсе командасы әгъзасы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 12 | Хажиәхмәтов Булат Зөфәр улы | Сколково проект идарәсе командасы әгъзасы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 13 | Анисимов Александр Николаевич | Сколково проект идарәсе командасы әгъзасы - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| 14 | Хәсәнов Булат Радик улы | Көнкүреш кластерының инвестиция проекты җитәкчесе - Зеленодольск муниципаль районы Проект комитеты әгъзасы (килешү буенча) |